**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Казан шәһәрендә БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуын уздыру чорында эш (хезмәт) вакытын оештыру турында**

Казан шәһәрендә БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуын уздыру чорында җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүне көчәйтү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектларында гамәлгә ашырыла торган чаралар турында» 2022 елның 19 октябрендәге 757 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 90, 94 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре территориясендә эшләүче (хезмәт эшчәнлеге алып баручы) түбәндәге затларга, хезмәт хакы түләүне саклап, 2024 елның 22 октябреннән 24 октябренә кадәр (бу көнне кертеп) эш көне булмаган көннәр билгеләргә:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын һәм башка вазыйфалар биләүче затларга;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары карамагындагы оешмалар хезмәткәрләренә.

2. Әлеге Указ эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары нигезендә 2024 елның 22 октябреннән 24 октябренә кадәр (бу көнне кертеп) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле органы, аның карамагындагы оешмалар эшен тәэмин итүче затларга кагылмый.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә әлеге Указның 1 һәм 2 пунктларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы булмаган Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары һәм алар карамагындагы оешмалар җитәкчеләренә 2024 елның 22 октябреннән 24 октябренә кадәр (бу көнне кертеп) чорда үз хезмәткәрләренең эш (хезмәт) вакытын әлеге

Указның 1 һәм 2 пунктларында билгеләнгәнгә тәңгәл тәртиптә оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Казан шәһәре территориясендә эшчәнлек алып баручы федераль дәүләт органнары, оешмалар (милекчелек рәвешенә карамастан) җитәкчеләренә 2024 елның 22 октябреннән 24 октябренә кадәр (бу көнне кертеп) чорда үз хезмәткәрләренең эш (хезмәт) вакытын әлеге Указның 1 һәм 2 пунктларында билгеләнгәнгә тәңгәл тәртиптә оештырырга тәкъдим итәргә.

6. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 07 август
№ 610